Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР № XXXVIII-5

Балык Бистәсе штп.

2023 елның 25 нче мае

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибе турында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2012 елның 24 февралендәге XV-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җирләрне мелиорацияләү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 28 декабрендәге 477-ФЗ номерле Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны билгеләү һәм туктату тәртибе турында» 2012 елның 24 февралендәге №XV-2 номерлы карарына (12.07.2012 № XVIII-8, 29.05.2017 №XIX-4, 22.07.2019 №XLIV-6 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктның 4 нче пунктчасында «дренаж» сүзеннән соң «һәм мелиоратив» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов